Алла САЛЬНИКОВА,
Диләрә ГАЛИУЛЛИНА

Алла САЛЬНИКОВА,
Диляра ГАЛИУЛЛИНА



ТАТАР «ӘЛИФБА»СЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

ТАТАРСКАЯ «АЛИФБА»: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОСТЬ

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

Фәнни мөхәррирдән

Беренче уку әсбапларын тикшерү-өйрәнү зарурлыгы 1940 еллар ахырында туа. Бельгиянең Конго өчен дәреслекләрен, Кытайның Маога кадәрге һәм аннан соңгы чор әлифбаларын, Аргентинадагы беренче дәреслекләрне, белорус һәм поляк әлифбаларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр әлифбаның әйләнә-тирә дөньяны танып белүдә юлкүрсәткеч булуын раслыйлар. Әлифба, чын мәгънәсендә, баланы дөньяга башка күз белән карарга өйрәтә. Алла Сальникова һәм Диләрә Галиуллинаның бу монографиясе татар балаларын укырга өйрәтүче дәреслекнең, аларны мөселман җәмгыяте, совет колхозлары, совет дәвереннән соңгы чор вәкилләре буларак социальләштерү чарасы булып, Татарстанның милли-мәдәни мирасын, милли традицияләрен саклап калып, дөньякүләм фән үсешендә танылуына юл ача.

Бу хезмәт советлардан соңгы чор мәдәнияте мәйданын, элеккеге СССР төбәкләренең хәзерге мәдәниятләре үсеш нигезләрен өйрәнүдә аеруча әһәмиятле. Тикшеренү советларга кадәрге һәм совет чорлары тәҗрибәсен, Татарстан Республикасының башлангыч мәктәп һәм мәдәният үсеше өлкәсе сәясәтендәге үзгәртеп коруларны колачлый. Әлеге үзгәрешләрнең, яңаны төзү, үзгәртеп кору турындагы, киләчәккә юнәлгән уй-фикерләрнең әлифба битләрендәге чагылышы кешелек җәмгыятендә барган мөһим процесслар турында сөйли.

Алла Сальникова һәм Диләрә Галиуллина мәгариф һәм балалар тормышын өйрәнү өлкәсендә күптәннән эшлиләр, һәм уңышлары да бар. Тәҗрибәле, кызыксынучан авторлар Россия историография фәнендә моңарчы кул җитмәгән өлкәдә шактый зур тәжрибә тупладылар.

А. Сальникова совет һәм советлардан соңгы чор балачак тарихы буенча рус телендә әлегә беренче монография әзерләп чыгарды. Д. Галиуллинаның революциягә кадәрге һәм беренче татар совет әлифбалары тарихына багышланган эзләнүләре игътибарга лаек. Ул — аларның библиографиясен төзүче дә. Әлеге басманың дөнья күрүе фән тарихында Россия өчен әлегә яңарак теманың үсеш алуын билгеләп кенә калмый, бәлки башка илләрнең мәгариф системасында да бара торган тарихи процессларны да Татарстан мисалында яхшырак күз алдына китерергә ярдәм итәр дип ышанам. Россия һәм дөньякүләм фән өлкәсендә мондый өйрәнүләргә ихтыяҗ зур. Алар, һичшиксез, әлифбадан соң килгән уку әсбапларын өйрәнүгә багышланган П. Габәлә, Л. Бәй, С. ле Мэн, П. Крейн, Ф. Пилярчик һ. б. немец, кытай, француз, америкалы, поляк галимнәренең классик хезмәтләре рәтеннән урын алыр.

В. Г. Безрогов,
педагогика фәннәре докторы,
РМАның Мәгариф үсеше
стратегиясе институты
баш фәнни хезмәткәре,
РМА әгъза-корреспонденты

От научного редактора

Потребность в научных исследованиях, посвящённых истории начальных учебных пособий, осознана в мировой историографии примерно с конца 1940-х гг. Исследования бельгийских учебников для Конго, домаоистских и маоистских букварей в Китае, учебников для начальных классов в Аргентине, белорусских и польских букварей и многие другие работы показали ценность и глубину такого источника как букварь, в котором взрослое общество моделирует своего рода путеводитель по окружающему миру. По сути своей букварь предназначен для того, чтобы стать для ребёнка своеобразным мостом в современный мир. Монография Аллы Сальниковой и Диляры Галиуллиной позволяет впервые сделать зримым в мировой науке учебник для обучения чтению татарских детей, инструмент их социализации как членов мусульманской общины, советских колхозов, постсоветского социального пространства, быстро урбанизирующегося, подверженного глобальной модернизации мира, в котором остаются воспоминания о прежних многовековых национальных традициях, позволяющих сохранять национальное культурное наследие в Татарстане.

Подобная работа особо значима для изучения постсоветского пространства, изучения той основы, на которой происходит развитие современных культур различных регионов бывшего СССР. Исследование соединяет в себе рассмотрение накопленного и выстраданного опыта предыдущих досоветского и советского периодов с реконструкцией политики в сфере начального образования и развития культуры в современном Татарстане. Развитие, реконструкция, переосмысление, пересоздание, конструирование в букваре культурных смыслов, иерархии ценностей, определений желательного и нежелательного будущего ярко показывает важные процессы, происходящие в обществе взрослых людей и «проговаривающиеся» в книжках для первоклашек.

Алла Сальникова и Диляра Галиуллина уже достаточно долго и успешно работают в сфере изучения истории образования и детства. Их профессиональные навыки, заинтересованность в исследованиях продемонстрировали научному сообществу серьёзные, можно даже сказать, пионерские для российской историографии результаты. А. Сальникова выпустила первую и пока единственную на русском языке монографию по истории детства в советское и постсоветское время. Д. Галиуллина проводит интереснейшие изыскания в области истории дореволюционных и первых советских татарских букварей, является составителем их библиографий. Я полагаю и уверен, что появление данной книги не только значительно продвинет эту пока ещё весьма молодую для России тему в исторической науке. Более того, пример Татарстана позволит лучше представить исторические процессы, проходящие в образовательных системах многих стран. В отечественной и мировой науке есть большая потребность в таком исследовании. Оно, несомненно, встанет в один ряд с классическими работами П. Габэле, Л. Бэй, С. ле Мэн, П. Крейн, Ф. Пилярчика и других немецких, китайских, французских, американских, польских исследований.

В. Г. Безрогов,
доктор педагогических наук,
главный научный сотрудник Института стратегии
развития образования РАО, член-корреспондент РАО

Авторлардан

Сез үзегезнең «Әлифба» китабын хәтерлисезме? Хәтерләмәүчеләр дә бардыр. Алайса, сорауны башкачарак биреп карыйк: мәктәптә иң беренче көнегезне хәтерлисезме? Агач яфракларын алтынга манып йөрүче сентябрь кояшы, я булмаса күктә ашыгып йөзгән алама болытлар һәм яңа матур мәктәп формасы өстеннән плащ яисә куртка кияргә мәҗбүр итеп сибәләгән вак яңгыр… Менә тантаналы линейка тәмам, сез, парлашып басып, укытучыга ияреп, сыйныф бүлмәсенә кереп утырасыз. Укытучы апагыз: «Ә хәзер, портфельләребезне ачып, «Әлифба» китабын алабыз һәм аның беренче битен ачабыз», – ди. Сез портфелегезне ачасыз, ә анда, яраткан уенчыгыгыз янында, матур китап –«Әлифба» ята. Ул сезне укырга, алай гына да түгел, Туган илебезне, үз халкыбызны яратырга өйрәтер, үзегезне кеше, граждан итә торган сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итәр. Текстлары бик гади, беркатлы, рәсемнәре дә сабыйлар өчен ясалган кебек тоелса да, аларда тирән мәгънә ята. «Әлифба» битләрендә үрнәк булырлык «идеаль» чынбарлык образы сурәтләнә. Юкка гына «Әлифба»ны барлык фәннәрнең башлангычы, төп мәгънәсендә, олы тормышның башы димиләр.

Һәр халыкның әлек тә, хәзер дә үз «Әлифба»сы бар, ул балаларның, еш кына янәшә гомер кичерүче башка милләт балаларының да дөньяны танып белүдәге әһәмиятле чарасы булып тора. Татар халкының 200 еллык тарихы булган «Әлифба» китабы Казан губернасы, Совет Татарстаны, советлардан соңгы чор Татарстаны, бөтен Идел-Урал регионында һәм аннан читтә дә киң таралган, мәдәниятара элемтәләрдә зур роль уйнаган.

Татар әлифбасы – милли мәгариф, тәрбия, агарту эшләренең аерылгысыз өлеше генә түгел, бәлки XX–XXI гасырларда барган сәяси эш-гамәлләр чагылышы да. Ул – милли хәтер һәм милли тәҗрибә күрсәткече, милли бердәйлеккә ирешү чарасы, чөнки дәреслек текстлары балаларга үз милләте һәм башка милләт балалары турындагы мәгълүматны җиткерә. Шул ук вакытта әлеге дәреслек күпмилләтле Татарстанда милләтара дуслыкны саклауның һәм ныгытуның, милләтләрнең үзара тыныч, тату яшәвенең – «Татарстан феномены»ның барлыкка килүендә дә зур роль уйнаган.

Татар «Әлифба»сы күп еллар дәвамында дидактиканың яки китап белгечләренең тикшеренү предметы гына булып килде. Аңа, гадәттә, милли мәдәният тарихы, мәгариф, китап басу, татар мәгърифәтчеләренең тормыш юлы турындагы хезмәтләрнең, белешмә басмаларның аерым бүлекләре багышлана иде. Тик әлегә кадәр «Әлифба»ны сәяси, мәдәни феномен буларак өйрәнүнең ни концептуаль аппараты, ни методикасы тәкъдим ителмәде, аның милли үзаң формалашудагы роле, чыганакларны өйрәнү потенциалы җентекләп тикшерелмәде. Без бу кимчелекләрне төзәтергә тиеш.

Идел Болгары чорында барлыкка килеп, XVIII гасырның соңгы чирегендә тагы да үсеш алган татар милли әлифбасы татар халкы белән бергә катлаулы юл үткән. Ул татар милләте, татарларда яңача укыту традицияләре формалашу

От авторов

Помните ли вы ваш первый школьный букварь? Думаем, что далеко не все ответят на этот вопрос утвердительно. Тогда зададим его по-другому: а помните ли вы ваш первый школьный день? Нежаркое сентябрьское солнце, золотящее верхушки деревьев, или быстро бегущие по низкому небу растрёпанные облака, или тихий моросящий серенький дождик, из-за которого пришлось спрятать новую школьную форму под плащом или курткой? И вот уже прошла торжественная линейка, и все парами потянулись за учительницей в классе и расселись за партами. И её слова: «А теперь откройте портфели, достаньте букварь и раскройте его на первой странице». Вы открываете портфель, а там, рядом с любимым плюшевым мишкой, который вместе с вами пришёл в школу в этот ваш первый школьный день, лежит Она – эта яркая нетолстая книга в твёрдой обложке, которая призвана научить не только читать, хотя и это, конечно, тоже важно. Её задачи гораздо сложнее и шире: Она призвана научить любить свою Родину, свой народ, наделить теми нетленными ценностями, которые делают человека человеком, а гражданина – гражданином. И пусть такими нехитрыми кажутся Её тексты, и такими простыми, как будто пришедшими из детских книг, картинки, все они несут глубокий смысл. Ведь на страницах букваря представлен образ некой «идеальной» реальности, которая призвана стать образцом и примером для подражания. И потому букварь есть не только «начало всех наук», как писал поэт, но по существу – начало всей взрослой жизни.

У каждого народа были и есть свои буквари, по которым учились читать и познавали мир его дети, а зачастую – и дети других этносов, живущих вместе с ним. У татарского народа это «Алифба» – букварь с более чем 200-летней историей, широко распространённый не только в многонациональном пространстве Казанской губернии, советской Татарии, постсоветского Татарстана и всего волго-уральского региона, но и далеко за его пределами и играющий важную роль в процессе межкультурных коммуникаций.

Татарский букварь представляет собой не просто неотъемлемый элемент национальных образовательных, воспитательных, просветительских, а применительно к XX–XXI вв. – отчётливо выраженных политических практик. Он является важнейшим источником по истории татарского народа, носителем национальной памяти и опыта, средством обретения национальной идентичности, поскольку формирование представлений о своём народе и других этносах у детей всегда происходило во многом через учебные тексты. В то же время этот учебник позволяет выяснить, насколько «Алифба», свободно функционирующая в уникальном мультикультурном пространстве Татарстана, способствовала складыванию, сохранению и укреплению межнациональной толерантности и особого «татарстанского феномена» гармонизации межнациональных отношений.

Национальный букварь на протяжении долгого времени был лишь предметом дидактического или книговедческого анализа. Ему обычно посвящались отдельные, довольно лаконичные сюжеты в общих работах по истории национальной культуры, образования, книжного и печатного дела, в персоналиях татарских просветителей и справочных изданиях. До сих пор не был предложен ни концептуальный аппарат, ни методология исследования татарского букваря и как политического

процессларында, алга таба – татар халкының «күпмилләтле социалистик Ватанның тугандаш халкы»на әверелүендә, аннан соң Татарстанның суверенлык яулау һәм бәйсезлек өчен көрәш процессында зур роль уйный. Нәкъ менә шуның өчен дә без «Әлифба»ның шактый зур чорны колачлаган тарихи-мәдәни «биография»сен торгызырга, төзергә тырыштык. Тикшеренүнең нигезе итеп XIX–XX гасырлар чикләрен[1] алдык. Әлеге чор татарның «милли яңарышы», җәдитчелек идеологиясенең таралган чоры, милли мәгариф һәм милли мәдәният өлкәсендәге казанышларны барлау, татар җәмгыятендә балачакка һәм балаларга яңача мөнәсәбәт туу, дөньяви уку әсбаплары, шул исәптән әлифбалар барлыкка килү чоры буларак характерлана. Хезмәтебез XXI гасыр башында Татарстанда татар балалары һәм рус телендә сөйләшүче балалар өчен аерым, яңа төр дәреслекләр эшли башлау чоры белән тәмамлана.

Тикшеренү нигезен Казан (Идел буе) федераль университеты Фәнни китапханәсендә, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә, шулай ук Арча педагогика көллиятендә (Татарстанның Арча шәһәре) 1998 елның сентябрендә ачылган Россиядә беренче уникаль Әлифба музеенда саклана торган татар әлифбалары тупланмалары тәшкил итә. Татар «Әлифба» китабының авторлары – С. Г. Вагыйзов һәм Р. Г. Вәлитова – озак еллар дәвамында шушы уку йортында эшләгәннәр.

Татар әлифбасын күпмилләтле Россия мәдәниятенең аерылгысыз өлеше һәм татар халкы тарихының тарихи чыганагы буларак карау Татарстан тарихын, татар милли мәгарифен, мәктәбен һәм балалар тормышын өйрәнүгә яңача якын килергә мөмкинлек бирә. Бу, – безнең карашыбызча, заманча һәм бик вакытлы хезмәт.

Шуны да әйтергә кирәк: хезмәт ике милли мәдәният вәкиле – татар һәм рус кешеләре тарафыннан башкарылды. Бу алдан ук килешенгән иде, чөнки нәкъ менә шундый диалог нәтиҗәсендә генә тулы һәм объектив гыйльми күзаллау туа дип уйлыйбыз. Әлеге китап, асылда, толерантлык һәм мәдәниятара бәйләнеш үрнәге булып тора.

феномена, и как феномена культуры, не изучалась его роль в формировании национального самосознания, не затрагивался и его источниковедческий потенциал.

Возникнув ещё в период Волжской Булгарии и достоверно существуя уже в последней четверти XVIII в., татарский национальный букварь прошёл сложный путь вместе с развитием самого татарского народа. Он сыграл исключительную роль в процессе становления татарской нации, в формировании татарской новометодной образовательной традиции, впоследствии в превращении татарского народа в «один из братских народов великой многонациональной социалистической Родины», а затем и в его борьбе за обретение суверенитета Татарстаном. Именно поэтому мы стремились воссоздать историко-культурную «биографию Алифбы» на протяжении длительного хронологического периода. Отправной точкой исследования явился рубеж XIX–XX вв.[1]. Это было время татарского «национального ренессанса», распространения идеологии джадидизма, время переосмысления достижений национального образования и культуры, кардинального изменения отношения татарского общества к детству и детям, появления и быстрого распространения новых, протосветских учебных изданий. Завершается книга началом XXI в., когда в Татарстане произошёл переход на новое поколение учебников, предназначенных как для татароязычных, так и для русскоязычных учащихся.

В основе данного исследования лежат коллекции татарских букварей, хранящиеся в Научной библиотеке им. Н. И. Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета, в Национальной библиотеке Республики Татарстан, а также в фондах уникального, единственного в России музея букваря – Музея «Алифбы» (г. Арск, Республика Татарстан), основанного в сентябре 1998 г. при Арском педагогическом колледже, где на протяжении долгих лет работали авторы одного из популярнейших татарских букварей – С. Г. Вагизов и Р. Г. Валитова.

Изучение татарского букваря как неотъемлемой части многонациональной российской культуры и важнейшего исторического источника по истории татарского народа будет способствовать распространению современных исследовательских подходов к изучению истории Татарстана, татарского национального образования, школы и детства. Оно представляется нам безусловно современным и своевременным.

Хотелось бы добавить, что это исследование было осуществлено представителями двух национальных культур – татарской и русской. Таковой и была первоначальная задумка, поскольку, по нашему мнению, именно в процессе диалога рождается более полное и объективное научное знание. Эта книга и есть, по существу, тот пример толерантности и межкультурного взаимодействия, о котором в ней пойдёт речь.

[1] Иске ысуллы тагы да элеккерәк татар әлифбалары аз санда һәм начар сакланган булу сәбәпле, күзәтү төсендә генә искә алыначак.

[1] В связи с плохой сохранностью и малочисленностью старометодных татарских букварей более раннего периода они будут рассмотрены в книге лишь обзорно.



I бүлек


«ИМАН ШАРТЫ»ННАН ЯҢА ТӨР ӘЛИФБАГА: XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР «ӘЛИФБА»СЫ

Глава I

ОТ «АЗБУКИ С МОЛИТВАМИ» К БУКВАРЮ НОВОГО ТИПА: ТАТАРСКАЯ «АЛИФБА» КОНЦА XIX – НАЧАЛА XX В.


XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар халкы тормышының барлык өлкәләрендә зур үзгәрешләр күзәтелә, шуңа күрә әлеге чор «милли яңарыш» дип характерлана да. Татар җәмгыятенең балачак һәм балаларга мөнәсәбәте төптән үзгәрә. Милләтебез зыялылары яңарышны нәкъ менә балалардан башларга кирәклекне аңлый башлыйлар. Мондый «балаларга игътибарны арттыру» борылышы алар өчен махсус татар педагогик әдәбияты барлыкка килүдә һәм балалар басмаларының күбәюендә, сыйфат үзгәрешендә чагыла.

В конце XIX – начале XX в. во всех сферах жизни татарского народа произошли столь существенные изменения, что это позволило определить данный период как время «национального ренессанса». Принципиально изменилось отношение татарского общества к детству и ребёнку. Национальная интеллигенция отчётливо осознавала, что первые шаги на пути «возрождения» нации необходимо начинать именно с детей. Такой «детоцентристский» поворот проявил себя и в появлении специальной татарской педагогической литературы о детях, и в существенном расширении и качественном изменении детских изданий.



• Г. Тукайның «Алтын әтәч» китабы тышлыгы. 1909

• Обложка книги Г. Тукая «Алтын әтәч». 1909



• Г. Тукайның «Юаныч» китабы тышлыгы. 1908

• Обложка книги Г. Тукая «Юаныч». 1908

XX гасыр башында дөнья күргән татарча басмаларның зур өлешен балалар өчен матур әдәбият китаплары тәшкил итә. Балалар өчен чыгарылган күп кенә әдәби китаплар ул заманда дәреслек булып та йөргән. Татар балаларын милли традицияләр нигезендә тәрбияләү һәм укыту, шулай ук аларны дөнья мәдәнияте казанышлары белән таныштыру процессында әлифба зур роль уйнаган.

1. «Яңа» татар әлифбасы һәм аның үзенчәлекләре

Татарларда мәктәптә белем бирү системасының шактый зур тарихы бар. Ул гасырлар дәвамында формалашкан, ә туган телдә укыту үсеп килүче буынга әхлакый тәрбия бирүнең төп нигезе дип саналган. Татар әлифбасының (гарәп алфавитының беренче хәрефләре – «әлиф» (ا), «ба» (ب) исемнәреннән алынган) да озын һәм катлаулы тарихы бар.

Тарихчылар һәм телчеләрнең татар язуына, китап басу эшенә, халык мәгарифенә кагылышлы күп кенә тикшеренүләрендә болгар-татар әлифбаларының Идел Болгары мәктәпләрендә, аннан соң Алтын Урда һәм Казан ханлыгында да кулланылулары турында ачык әйтелә. Кызганыч, Урта гасырлар татар әлифбалары сакланмаган. Шуңа күрә әлеге раслаулар турыдан-туры булмаган дәлилләргә – Урта гасырларда яшәгән гарәп һәм татар авторлары хезмәтләрендәге XII–XIV йөзләрдә татарларда белем бирү оешмаларының тармаклы челтәре булуы турындагы мәгълүматларга таяна. X гасырда ук гарәп-фарсы сәяхәтчесе Ибне Рустә Идел Болгарында мәчетләр генә түгел, ә «мәзин һәм имамнары булган»[1] башлангыч уку йортлары турында яза. Соңрак мәдрәсәләр дә барлыкка килә.

Мәктәп һәм мәдрәсәләр Алтын Урда һәм Казан ханлыгында да булган. Кызганыч ки, әлеге дәүләтләрнең мәгариф системасын яктырткан язма истәлекләр сакланмаган. Шулай да Казанның үзәк мәхәлләсе каршында Кол Шәриф җитәкчелегендәге шактый зур мәдрәсә эшләве мәгълүм. Укытуның эчтәлеге һәм формалары турында мәгълүматлар сакланмаган, ләкин шунысы билгеле: укыту дини төстә алып барылган һәм башка мөселман илләрендәге укытудан аерылмаган диярлек. Төп игътибар дин тәгълиматын өйрәнүгә юнәлтелгән. Монда гарәп графикасында язарга һәм укырга өйрәнгәннәр, Коръән, хәдисләр һәм башка

Художественная детская литература была самой многочисленной среди всех изданий на татарском языке начала XX в. Хотя многие книги, предназначенные для детского чтения, использовались и как учебники, букварю среди детских изданий того времени отводилось особое место как в процессе образования и воспитания татарских детей в национальных традициях, так и в приобщении их к достижениям мировой культуры.

1. «Новый» татарский букварь и его особенности

Система школьного образования у татар имела глубокие исторические корни и формировалась на протяжении столетий, а обучение на родном языке рассматривалось как одна из основ нравственного воспитания подрастающего поколения. Татарский букварь – Әлифба (от названия первой буквы арабского алфавита – «әлиф» (ا) и второй – «ба» (ب), также имел долгую и непростую историю, уходящую своими корнями в далёкое прошлое.

В большинстве исследований историков и филологов, касающихся истории формирования татарской письменности, книжного дела и народного образования, прямо говорится об использовании булгаро-татарских букварей ещё в мектебах Волжской Булгарии, а затем в Золотой Орде и Казанском ханстве. Сами средневековые татарские буквари, к сожалению, не сохранились. Поэтому данные утверждения опираются в основном на косвенные свидетельства, содержащиеся в трудах арабских и татарских средневековых авторов, сведения о наличии разветвлённой сети татарских образовательных учреждений в XII–XIV вв. Ещё в начале X в. арабский путешественник и географ Ибн Русте писал о наличии в Волжской Булгарии не только мечетей, но и начальных учебных заведений «с муэдзинами и имамами»[1]. Позднее появились и медресе. Так, известно о существовании крупного медресе при центральной соборной мечети Казани, возглавляемой сеидом Кул Шарифом. Подробных сведений о содержании и формах обучения не сохранилось, однако очевидно то, что они носили в основном религиозный характер и мало чем отличались от преподавания в других мусульманских странах. Особое внимание уделялось изучению богословия. Здесь учились читать и писать на арабской графике, осваивали те нормы арабского языка, которые были необходимы для чтения Корана, хадисов и других религиозных книг. Преподавание велось методом толкования Корана (тадрис) и, частично, диктованием (имла). Поскольку в таких учебных заведениях учились не только будущие религиозные деятели, но и государственные служащие,

дини китапларны уку өчен кирәк булган гарәп теле кагыйдәләрен үзләштергәннәр. Укыту (тәдрис) Коръәнне аңлату һәм, өлешчә, дөрес язарга өйрәтү (имла) ысулларына таянган. Бу уку йортларында булачак дин әһелләре генә түгел, ә бәлки дәүләт хезмәткәрләре, сәүдәгәрләр, галимнәр дә укыган. Монда дөньяви фәннәрдән математика, астрономия, тарих, география, медицина укытылган. Гарәп теле белән беррәттән, XI гасырдан башлап, Шәрык әдипләре һәм шагыйрьләре теле — фарсы теле өйрәтелгән.

Татар дәүләтчелеге бетү белән, фән, мәдәният һәм милли мәгариф традицияләренең дә юкка чыгу куркынычы арта. Мәктәп системасына да шактый зыян килә. Аның бөтенләй юкка чыгу ихтималы зур була. Казандагы татар уку йортларының эшчәнлеге турында 1552 елгы вакыйгалардан алып XVIII гасырның соңгы чирегенә кадәр вакыт аралыгын чагылдырган мәгълүмат юк диярлек. Алар эшчәнлекләрен дәвам иткәннәрдер, бәлки, һәрхәлдә, ярымлегаль рәвештә. Мәчетләр төзү туктатыла. Балаларны урманнарда, мунчаларда укыта башлыйлар, «карчыкларга һәм суфиларга»[2] укытырга бирәләр. Әмма Казан татарлары белем бирүдә милли традицияләрен саклап кала алганнар. Бу юнәлештә мөселман дин башлыклары зур көч куйганнар.

Татар халкында белем бирү, уку-укыту традицияләренең яңаруы XVII—XVIII гасырлар чигендә башлана, ләкин мәчетләр төзү һәм алар каршында мәдрәсә ачуга рәсми рөхсәт XVIII гасырның 70 нче елларында гына бирелә. Казан губернасында уңай үзгәрешләр 1767 елда Казанга Екатерина II килеп киткәч башлана. Шундый уңай үзгәрешләрнең берсе дип 1769 елда Казанда Беренче ирләр гимназиясендә махсус татар сыйныфы ачылуны әйтергә кирәк. Шундый ук сыйныф Әстерханда Беренче ирләр гимназиясендә дә ачыла. Татар телен белү, башка Көнчыгыш телләрен тиз һәм уңышлы үзләштерү өчен, бик әһәмиятле дип таныла. Ул киләчәктә дипломат булып эшләргә җыенучы шәкертләргә аеруча зарури саналган, Көнчыгыш илләре белән ул чорда дипломатик татар телендә хәбәрләшкәннәр, хатлар язышканнар.

Рус гимназияләрендә татар телен өйрәтү нәкъ менә «Әлифба»дан башланган. 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә рус гимназиясендә татар телен укыту өчен беренче әлифба басыла, ул болай исемләнә: «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочинённая каторговцы, учёные, здесь преподавались и светские предметы — математика, астрономия, история, география, медицина. Наряду с арабским — языком Корана, начиная с XI в. изучался и персидский как основной язык, на котором сочинялись художественные произведения на Востоке.

С утратой татарской государственности появилась реальная угроза потери основных достижений науки, культуры и национальных образовательных традиций. Сильно пострадало и школьное образование. Казалось, ещё немного и оно погибнет совсем. Сведения о деятельности татарских учебных заведений после трагических событий 1552 г. вплоть до последней четверти XVIII в. почти отсутствуют. Можно предположить, что они продолжали свою работу, но полулегально. Возведение мечетей было запрещено: «народ впал в невежество». Детей стали обучать в лесах, банях или отдавали на обучение «старухам и суфиям»[2]. Несмотря на все преграды, казанским татарам удалось сохранить национальные образовательные традиции. Большую роль в этом сыграло мусульманское духовенство.

Возрождение образовательных традиций татарского народа началось на рубеже XVII—XVIII вв., однако официальное разрешение на строительство мечетей и открытие при них медресе было получено лишь в 70-х гг. XVIII в. В Казанской губернии существенные перемены стали особенно наглядно проявляться после посещения Екатериной II Казани в 1767 г. Одним из таких положительных новшеств стало открытие в 1769 г. специального класса татарского языка в Первой казанской мужской гимназии. В 1789 г. такой же класс был открыт и в Первой астраханской мужской гимназии. Знание татарского языка признавалось необходимым в качестве базового для более лёгкого и успешного овладения другими восточными языками. Пригождалось оно и будущим дипломатам, поскольку татарский язык традиционно использовался в ходе дипломатической переписки с восточными странами.

Изучение татарского языка в русских гимназиях начиналось именно с букваря. В 1778 г. в типографии Московского университета печатается первый букварь для обучения учащихся русских гимназий татарскому языку — «Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочинённая казанских гимназий учителем и адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная». Автором учебника, как следует из его названия, был преподаватель татарского языка Первой казанской мужской гимназии, педагог-просветитель Сагит Хальфин (1732—1785). В 1787 г. поя-

занских гимназий учителем и адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная». Исеменнән күренгәнчә, «Азбука…»ның авторы Казанның Беренче ирләр гимназиясе укытучысы Сәгыйть Хәлфин (1732–1785) була. С. Хәлфин төзегән икенче дәреслек – «Әлифбаи татар» 1787 елда дөнья күрә. Мондый дәреслекләрнең дөньяга чыгуы татар уку әсбапларына булган ихтыяҗны, мөгаен, канәгатьләндергәндер; XVIII гасырның соңгы чирегендә татар әлифбасына ихтыяҗ зур була, ә дәреслекләр җитешми. Гимназистларны татар әлифбасы белән тәэмин итү мәсьәләсе ул чорда хәл ителмәсә дә, басма әлифба тарихы С. Хәлфиннең балаларны (өлешчә зурларны да) татар грамотасына өйрәтү өчен төзелгән үзенчәлекле, оригиналь дәреслегеннән юл ала.

1804 елда, дәреслекләргә ихтыяҗны истә тотып, С. Хәлфиннең оныгы Ибраһим Хәлфин (1778–1829) төрек, гарәп һәм фарсы язуы белән танышу мөмкинлеген ачкан «Азбука и этимология татарского языка» хезмәтен, ә 1809 елда «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в императорской Казанской гимназии» дип аталган дәреслек бастырып чыгара. Әлеге кулланманы чын мәгънәсендә әлифба дип әйтеп булмый әле. Ул, нигездә, әхлакый-этик һәм иҗтимагый-сәяси принципларны чагылдырган дини эчтәлекле текстлардан торган. Мәсәлән, «Кем Алладан курыкса һәм намус кушканча яшәсә, ул һичкемнән курыкмас. Аллага ихлас күңелдән ышану һәм аны ярату кирәк. Аллаһыны зурла һәм аны тыңла»[3].

Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфин дәреслекләре ориенталистика фәнендә Россиядә генә түгел, бөтен Европада беренче басма әсбаплар булып саналалар: француз ориенталисты Сильвестр де Сасиның (1758–1838) «Арабская грамматика»сы 1810 елда гына басылып чыга. Әмма бу хезмәтләр татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен чыгарылмаган.

Соңрак рус телле укучылар өчен Г. Баһаповның «Мөгаллим әүвәл фи тәгълим лисан әл-гарәп вә әл-фарси әт-татари» (1859) һәм М. Бикчуринның «Татарларга русча, урысларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч» (1887) дәреслекләре дөнья күрә.

Татар әлифбасын өйрәнүгә күренекле рус педагогы, мәгърифәтче Н. И. Ильминский (1822–1891) зур өлеш кертә. Ул керәшен вился ещё один букварь, составленный С. Хальфиным – «Әлифбаи татар» («Татарский букварь»). Появление этих учебников должно было хоть в какой-то степени ликвидировать ощутимый дефицит такого рода учебных пособий: уже тогда, в последней четверти XVIII в., татарская азбука была достаточно широко востребована, но учебников не хватало. Хотя поставленная задача по обеспечению гимназистов татарским букварём в то время так и не была решена, но именно с появлением «Азбуки» Сагита Хальфина началась история татарского печатного начального учебника как особого, оригинального издания по обучению детей (а отчасти и взрослых) татарской грамоте.

В 1804 г. в связи с продолжающейся нехваткой учебников внук Сагита Хальфина Ибрагим (1778–1829) опубликовал «Азбуку и этимологию татарского языка», где также можно было ознакомиться с турецким, арабским и персидским письмом, а в 1809 г. – «Азбуку и грамматику татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в императорской Казанской гимназии». Этот учебник не являлся букварём в полном смысле слова. Он включал в себя в основном религиозные тексты, содержавшие морально-этические и социально-политические принципы, которым должны были следовать учащиеся: «Кто Бога боится и честно поступает, тот не страшится ничего. Уповать на Бога и любить Его всем сердцем должно. Государя своего почитай и повелениям его повинуйся»[3].

Учебники Сагита и Ибрагима Хальфиных были первыми печатными учебными изданиями в области ориенталистики не только в России, но и в Европе: ведь знаменитая «Арабская грамматика» французского ориенталиста Сильвестра де Саси (1758–1838) была опубликована лишь в 1810 г. Однако эти учебники не были предназначены для мектебов и медресе.

Впоследствии для русскоязычных учащихся были подготовлены такие учебные издания, как: «Мөгаллим әүвәл фи тәгълим лисан әл-гарәп вә әл-фарси әт-татари» («Пособие для начинающих изучение арабского, персидского и татарского языков», 1859) Г. Вагапова и «Татарларга русча, урысларга татарча сөйләшергә һәм үзлегеннән укырга өйрәткеч» («Татарско-русский и русско-татарский самоучитель», 1887) М. Бикчурина.

Большой вклад в татарскую букваристику внёс русский востоковед и педагог-миссионер Н. И. Ильминский (1822–1891), но его буквари предназначались лишь для отдельно взятой группы татарского населения – крещёных татар, т. к. появление этих учебников было обусловлено сугубо политическими причинами: с начала XIX в. началось массовое возвращение крещёных татар

татарлары өчен дәреслек төзеп чыгара. Әлеге дәреслекнең дөнья күрүе сәяси сәбәпләр белән аңлатыла. XIX гасыр ахырында керәшен татарларының күпләп исламга кайтуы күзәтелә башлый. Чиркәү һәм хөкүмәт чаң суга. Чиркәү руханиларының җирле халык телләрен белмәүләре хәлне тагы да катлауландыра. Россия империясенең рус булмаган халыкларын «агарту» эшләренә куркыныч яный. Шушы шартларда педагог-миссионер Н. И. Ильминский бик җитди тәкъдим белән чыга: православие тәгълиматы китапларын халыкның җанлы сөйләм теленә тәрҗемә итәргә, һәм, тәрҗемә иткәндә, гарәп язуыннан түгел, бәлки кириллицадан файдаланырга. Ул, башка халыкларның туган телләрен һәм әлифбаларының да кириллицада төзелүен исәпкә алып, укытуның аерым системасын уйлап таба.

Керәшен татарлары өчен кириллицада язылган беренче әлифба 1862 елда басылып чыга. Н. И. Ильминский әлеге басманың дини эчтәлектәге текстлардан гыйбарәт икәнлеген дә яза[4]. Анысы хак.

в ислам. Церковь и власть забили тревогу. Одной из причин такого явления, по их мнению, являлась языковая проблема, так как православные священнослужители не владели татарским языком и не могли, естественно, использовать его при общении с татарским населением. «Христианское просвещение» нерусских народов Российской империи оказалось под угрозой. В этих условиях педагог-миссионер Н. И. Ильминский выступил с принципиально важным для миссионерской работы предложением: православные богослужебные книги следует переводить на живой разговорный народный язык и пользоваться при переводе не арабским шрифтом, а кириллицей. Он разработал особую систему обучения для инородческих школ с учётом родного языка обучающихся, буквари для которых также создавались на основе кириллицы.

Первый татарский букварь на кириллице, предназначенный для крещёных татар, был опубликован в 1862 г. Н. И. Ильминский писал, что это издание представляет собой учебник «со статьями христианского, вероучительного и молитвенного содержания»[4]. Так оно и было.



• Казан губернасы Чистай өязе Шама авылында чиркәү карамагындагы рус-татар-чуваш мәктәбендә дәрес вакыты. XX гасыр башы
(Р. Р. Исхаковның «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья» китабыннан. Казан, 2011)

• Занятия в смешанной (русско-татарско-чувашской) церковно-приходской школе в д. Шама Чистопольского уезда Казанской губернии. Начало XX в.
(из книги Р. Р. Исхакова «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья». Казань, 2011)



• Казан губернасы Чистай өязе Актау авылы «Изге Гурий борадәрлеге» керәшен-татар мәктәбендә чиркәү җырлары дәресендә. XX гасыр башы (Р. Р. Исхаковның «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья» китабыннан. Казан, 2011)

• Урок церковного пения в крещёно-татарской школе «Братства Св. Гурия» в с. Белая Гора Чистопольского уезда Казанской губернии. Начало XX в. (из книги Р. Р. Исхакова «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья». Казань, 2011)



• Казан губернасы Мамадыш өязе Лые-Шия авылында «Изге Гурий борадәрлеге» керәшен-татар мәктәбе. XX гасыр (Р. Р. Исхаковның «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья» китабыннан. Казан, 2011)

• Крещёно-татарская школа «Братства Св. Гурия» в д. Лые-Шия Мамадышского уезда Казанской губернии. Начало XX в. (из книги Р. Р. Исхакова «Миссионерство и мусульмане Волго-Камья». Казань, 2011)

Бу әлифбаның беренче басмасы лингвистик кимчелекләрдән азат булмый. Аңа күп кенә гарәп һәм фарсы сүзләре кертелә, татар сүзләренең язылышында да хаталар күзәтелә. 1864 елда дәреслек төзәтеп бастырыла. 1874 елда керәшен татарларына атап яңа әлифба («Җазыу белдереў») чыгарыла, анда инде, татарча текстларны рус хәрефләре белән язу өчен, алфавит һәм хәрефләрнең язылыш нормалары бирелә. Әлифбаның беренче басмасында бирелгән, рус алфавитында булмаган, әмма татар теленең үзенчәлекле авазын белдергән «ң» хәрефе янына татар теленең [ә], [ү], [ө] авазларын белдерүче «ä», «ў», «ö» хәрефләре өстәлә.

Бу дәреслек 11 мәртәбә (1882, 1884, 1887 һәм аннан соңгы елларда) басылып чыга, һәм 1917 елга кадәр керәшен татарларын грамотага өйрәтү буенча бердәнбер әсбап булып йөри. Керәшеннәр татар теленең кириллицадагы әлифбасыннан Совет власте урнашканнан соң да файдаланалар. Соңрак 1930 еллар азагында Н. И. Ильминский тәкъдим иткән алфавитка нигезләнгән «яңа» кириллицалы татар язуы барлыкка килә.

Ул чорда Ильминский системасына төрле карашлар яшәвенә карамастан, озакка сузылган бәхәсләрдән соң ул рәсми рәвештә Россиядә яшәүче рус булмаган халыкларны укытуда төп метод буларак таныла. Кириллицага нигезләнгән әлифбалар Идел буенда чукындырылган башка халыклар һәм тагын башкортлар (1907), кыргызлар өчен (1908) дә төзелә.

Татар мөселман халыклары өчен мәктәп әлифбалары XIX гасыр башында гына нәшер ителә. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, XVIII гасыр урталарыннан Мортаза бине Котлыгыш һәм Ишнияз бине Ширниязның кулъязма әлифбалары киң таралган була.

Казанда 1802 елда 11 мең данә тираж белән басылган татар әлифбасы «Әттәһөҗи»не (дога китабын) сакланып калган күренекле басма китапларның берсе дип әйтергә кирәк. Ул китап бик популяр булып, ел саен диярлек зур тираж белән нәшер ителгән. Соңрак ул «Әлифба Иман шарты белән» яисә «Иман шарты» дигән исем астында чыга башлый. Татарлар аны гади генә «Әлифба» (яки «Әлеп би», «Әлпи») дип йөрткәннәр. Шуннан соңгы 125 ел дәвамында (аның соңгы басмасы 1928 елда дөнья күрә) китап үзгәрешсез диярлек чыгып тора. Үзгәрешләр дә фәкать алдагы басмаларда урын алмаган догалардан гына гыйбарәт була. Халык әлифбаның телен «китап теле» дип атаган – чыннан да, бу озак


Первое издание букваря имело ряд недостатков лингвистического характера. В букварь вошло много непонятных для простых людей арабских и персидских слов, не все татарские слова были правильно написаны на кириллице. В исправленном виде учебник был опубликован в 1864 г. В 1874 г. появился новый букварь для крещёных татар («Җазыу белдереў»), в котором окончательно были оформлены алфавит для передачи татарских текстов русскими буквами и нормы написания. В дополнение к букве «ң», отсутствовавшей в кириллице, но необходимой для воспроизведения фонетических особенностей татарского языка, появившейся в первом издании букваря, под специфические звуки татарского языка «ә», «ү», «ө» были приспособлены такие буквы русского алфавита, как «ä», «ў», «ö».

Этот учебник переиздавался 11 раз (в 1882, 1884, 1887 гг. и позднее) и вплоть до 1917 г. был единственной азбукой, используемой для обучения грамоте крещёных татар. Созданной Ильминским кириллической азбукой татарского языка кряшены продолжали пользоваться и с приходом советской власти. Позднее, в конце 1930-х гг., предложенный Н. И. Ильминским алфавит был использован для создания «новой» татарской кириллической письменности.

Несмотря на неоднозначное отношение современников к системе Ильминского, после продолжительных дискуссий она была официально признана основным методом обучения инородцев России (за исключением татар-мусульман). Буквари на основе кириллицы были разработаны для других крещёных народов Поволжья, а также для башкир (1907) и киргизов (1908).

Что касается букварей для татарского мусульманского населения, то первые печатные издания для мектебов появились только в начале XIX в. Как указывают исследователи, со 2-й половины XVIII в. известны лишь широко распространённые в татарской среде рукописные алифба Муртазы Кутлугуша (Котлыгыша) и Ишнияза бин Ширнияза.

Первым из известных сохранившихся печатных букварей для мектебов считается изданная в Казани тиражом в 11 тыс. экземпляров в 1802 г. татарская азбука «Аттагоджи» («Әттәһөҗи» – «Азбука, чтение по слогам») с молитвами для чтения. Книга была очень популярной и издавалась почти ежегодно большими тиражами. В дальнейшем книга стала выходить под названиями «Әлифба иман шарты белән» («Азбука с молитвами»), «Шараит аль-иман» или «Иман шарты» («Условия веры»). Татары называли её просто – «Әлифба» (или же «Әлеп би», «Әлпи»). На протяжении последующих 125 лет (последнее издание книги вышло в 1928 г.)





- «Иман шарты» дини әлифбасының беренче ике бите. 1812
- Первые две страницы религиозного букваря «Иман шарты». 1812

вакытлар буе әдәби тел булып яшәгән рәсми дини тел булган[5].

Дәреслекнең авторлары турындагы мәсьәлә озак вакытлар бәхәсле булып тора. Билгеле бер чыганаклар аны Мамадыш өязе Мортаза бине Котлыгыш әс-Симетигә (XVII гасыр азагы – XVIII гасыр башы), кайберәүләр Каргалы мәдрәсәсе хәлфәсе Ишнияз Ширниязга нисбәт итә. Һәрхәлдә, шунысы хак: 1890 елларга кадәрге вакыт аралыгында әлеге әлифба татар халкын укырга һәм язарга өйрәтә торган бердәнбер уку әсбабы булган.

Мөселман дин башлыклары «Иман шарты»н изге китап дип санаганнар. Анда ике мөселман кешесенең кара-каршы сөйләшүе рәвешендә дин тәгълиматының төп кануннары урын алган.

Рус миссионерлары да бу әлифба турында уңай фикердә булганнар. Миссионер Евфимий Малов 1894 елда аны рус теленә тәрҗемә итә. Үзенең «Мухаммеданский букварь» (1894) хезмәтендә ул «Иман шарты»н «Начальное учение человеком, хотящим разумети божественного писания» (1634) исемле рус схоластик азбукасы белән чагыштыра. Догалардан торган китапның эзлекле эчтәлегенә зур бәя биреп, ул аның полиграфик сыйфаты түбәнрәк булуын да искәртә. «Иман шарты»нда, ди Е. Малов, хәреф хаталары күп, китап начар сыйфатлы сары юка кәгазьгә тонык шрифт белән басылган[6].

Е. А. Малов, үзенә каршы килеп, бер яктан, китапның күп тапкырлар басылып киң таралуына шикләнеп каравын белдерә, икенче яктан, бер дәреслектән генә файдаланучы татарларны үрнәк итеп куя, чөнки ул чорда рус әлифбалары 2–3 ел саен үзгәреп торган. Яңадан бастырып чыгаруның сәбәбен ул китапка ихтыяҗ зур булуында түгел, ә бәлки аны тыюларыннан куркуда күрә. Чынлыкта исә, Е. Малов раславынча, татар әлифбасы эчтәлегендә «бу балалар китабын рус хөкүмәте тыярлык һичнинди сәбәп булмый[7]».

Өстәвенә әлеге әлифба, башка теләсә нинди татар китабы шикелле үк, Россия империясендә «рус булмаган халыкларныкы» категориясеннән йөргән, аны тыюларыннан курку да шуның белән аңлатылган булса кирәк.

Әлифба адресына җиткерелеп торган тәнкыйди фикерләр аның бизәлеше-эшләнешенә генә түгел, ә эчтәлегенә дә кагылган. XIX гасыр азагында дини әлифба алдынгы фикерле татар зыялыларын канәгатьләндерми башлый.

эта книга издавалась без существенных изменений. Вносимые дополнения представляли собой лишь ранее не включённые в это издание молитвы. Язык книги в народе называли «книжным» – это был официальный религиозный язык, долгое время являвшийся и литературным языком[5].

Вопрос об авторстве учебника на протяжении долгого времени оставался дискуссионным. Одни источники приписывали авторство учебника жителю Мамадышского уезда Муртазе бин Кутлугуш ас-Симети (конец XVII – начало XVIII в.), другие – хальфе Каргалинского медресе Ишниязу бин Ширниязу. Как бы то ни было, бесспорно одно: вплоть до 1890-х гг. это был практически единственный букварь, по которому учились читать и писать широкие слои татарского населения.

Мусульманское духовенство считало «Иман шарты»» «священной» книгой. В ней в виде беседы между двумя мусульманами в форме кратких вопросов и ответов излагались основные положения мусульманского вероучения.

Положительно отзывались об этом букваре и русские миссионеры. Так, в 1894 г. миссионер Евфимий Малов перевёл его на русский язык. В воей работе «Мухаммеданский букварь» (1894) он сравнивал «Иман шарты» с русской схоластической азбукой «Начальное учение человеком, хотящим разумети божественного писания» (1634). Высоко оценивая лаконичность содержания книги, состоявшей из религиозных молитв, он в то же время отмечал низкое полиграфическое качество издания. Малов писал, что «Иман шарты» издаётся «мухаммеданами очень невнимательно, со многими корректурными ошибками, на плохой, желтоватой и неплотной бумаге, избитым и слепым шрифтом»[6]. Противореча сам себе, Е. А. Малов скептически относился к излишней, по его мнению, многочисленности и массовости переизданий книги, хотя тут же призывал брать пример с татар, которые почти все обучались по одному учебнику, в то время как русские буквари менялись каждые два-три года. Причину переизданий он усматривал не в востребованности учебника, а в боязни его запрета. На самом же деле «мухаммеданский букварь», как утверждал Е. Малов, «ничего не содержит, что подавало бы серьёзный повод русскому правительству запрещать печатание этой детской книжки»[7]. Между тем этот букварь, как и любая другая книга на татарском языке, относился в Российской империи к категории «инородческих», что в какой-то степени и объясняло страх перед его запретом.

Однако высказываемая в адрес этого букваря критика чаще была вызвана не столько его оформлением, сколько его содержанием – в конце XIX в. религиозный букварь уже не отвечал ус-

1785 елда Казанда ирләр гимназиясе каршында беренче татар типографиясе (тарихта ул «Азия типографиясе» яисә «Гимназия типографиясе» буларак билгеле) ачылу һәм аның тулы куәткә эшли башлавы, шулай ук шәхси басмаханәләрнең ачылуы да татар әлифбаларының күпләп басылуына китерә. «Азия типографиясе»ндә беренче өч елда гына да «11 мең данә татар әлифбасы нәшер ителә»[8]. 1828 елда әлеге типография Казан император университетының хөкүмәт тарафыннан юмарт финанслана торган типографиясе составына кергәч, татар басмалары, шул исәптән дәреслекләр дә күпләп басыла башлый: 1855–1864 елларда типография 1 084 320 экземпляр татар китабы бастырып чыгара, ә XX гасыр башына елына 2 млн китап чыгарыла. Әлифбаларның ул чорда зур тираж белән басылуы укыту ихтыяҗы белән бәйле була: мәктәпләрдә малайларны да, кызларны да укытканнар (малайларны, гадәттә, — мулла, кызларны исә аның хатыны остабикә укыткан), 2 ел дәвамында әлифба иҗекләп укылган, аннан соң инде балалар Коръән һәм дини-әхлакый эчтәлектәге башка китапларны укырга керешкәннәр.

Татарларда белемгә омтылу һәм китап басу эше XIX–XX гасырларда милли үзаңның үсеш кичергән чорында аеруча активлашып китә. Бу процесс белем бирү системасындагы җәдит мәктәп-мәдрәсәләре тарафыннан кадими ысуллы уку йортларының кысрыклануы төсендә гамәлгә ашырылган реформа белән бергә барган. Яңа ысуллы мәктәпләр баштарак бик аз булса да, 1905 елдан соң Идел буе һәм Урал алды зур шәһәрләренең күп кенә милли мәктәпләрендә укытуда аваз ысулы кулланыла башлый. Соңрак андый тип мәктәпләр авылларда да барлыкка килә.

Билгеле булганча, иске ысуллы мөселман мәктәпләрендә укытуда хәрефләрне кушып — иҗекләп уку ысулы кулланылган. Шуңа күрә балалар йөгерек укырга тиз генә өйрәнә алмаганнар.

XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында эшләгән кадими мәктәп-мәдрәсәләр турында шактый күп мәгълүмат сакланган. Һәр балага диярлек башлангыч белем алырга мөмкинлек булган.

Ир балаларны укыту мәҗбүрирәк саналган, әмма киләчәктә балаларны милли традицияләр һәм ислам йолалары буенча тәрбияләү җаваплылыгы йөкләнәчәк кыз балаларга да уку мөмкинлеге тудырылган. Мөселман мәктәпләрен тоту дәүләт карамагында булмаганлыктан, балаларын укыткан өчен, ата-ана-

стремлениям и потребностям передовой татарской интеллигенции.

С момента открытия в 1785 г. первой в Казани татарской типографии при мужской гимназии (известной как «Азиатская» или «Гимназическая») и наращивания её мощностей, а также с появлением в Казани татарских частных типографий количество издающихся татарских букварей существенно возросло. Только за первые три года своего существования татарская типография при гимназии напечатала более «11 тыс. букваря на татарском языке»[8]. В 1828 г., когда эта типография вошла в состав щедро финансируемой властями типографии Императорского Казанского университета, издание татарской литературы, в том числе и учебной, достигло в Казани небывалых объёмов: только за 1855–1864 гг. типография напечатала 1 084 320 экземпляров татарских книг, а к началу XX в. стала издавать до 2 млн книг в год. Высокие по тому времени тиражи букварей обусловливались их востребованностью: обучение грамоте в мектебах и мальчиков, и девочек (мальчиков обычно обучал мулла, а девочек — его жена — «остабикә») обязательно включало использование букваря «со складами», которое продолжалось примерно два года. Затем дети переходили к чтению Корана и ряда других книг религиозно-нравственного содержания.

Особенно активно развивается татарское образование и издательское дело на рубеже XIX–XX вв., когда происходит трансформация татарского этноса в нацию («миллят») в современном для того времени понимании этого слова. Этот процесс сопровождался реформой национальной системы школьного образования, вылившейся в постепенное вытеснение старометодных (кадимистских) религиозно-богословских учебных заведений новометодными (джадидскими) мектебами и медресе. Первоначально новометодных школ было немного, но после 1905 г. во многих национальных школах крупных городов Поволжья и Приуралья стал использоваться звуковой метод обучения. Позднее такие школы стали появляться и в сельской местности.

Основным отличием практики обучения грамоте в старометодных мусульманских школах было, как известно, использование «иджики» — буквослагательного (буквенного) метода обучения, поэтому дети долго не могли научиться бегло читать.

О старометодных мектебах и медресе XIX — начала XX в. сохранилось достаточно большое количество сведений. Начальное образование было доступно практически каждому ребёнку. Обучение мальчиков считалось более необходимым, но девочки тоже имели возможность учиться, ведь именно на них ложилась ответственность за воспитание де-

лар мулла белән абыстайга бүләк яисә сәдака китерә торган булалар. Мөмкинлегенә карап, бу акча, товар, азык-төлек булган, әйтергә кирәк, уку өчен түләүнең мондый чарасы хисабына мәктәп-мәдрәсәләр киң колачлы «Россиянең иң ярлы авыл-салаларында да»[9] эшли алганнар.

Г. Тукай, бала чагы турында сөйләгәндә, Кырлайда аны тәрбиягә алган әнисенең, «укыган өчен, ике бөтен икмәк һәм нибары берме, әллә ике тиенме акча бирүен» әйтә. Иң гаҗәбе шунда: ул заманда ир һәм кыз балалар аерым укысалар да, кечкенә Габдулла кызлар белән бергә укуы турында яза: «Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында, минем яшемдәге кечкенә кыз балалар күп булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богъдай арасындагы берничә борчаклар кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде». Иң элек балалар гарәп алфавитын ятлаганнар, аннары «Иман шарты»н укырга керешкәннәр. «Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарты» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым», – дип яза Г. Тукай. Габдулланы бер елдан мәдрәсәгә күчерәләр. Малай яхшы укый. «Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга тугры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар»[10].

Мәдрәсәдә уку шәкертнең уңышлары һәм мөмкинлекләреннән торган, унар ел, хәтта аннан да озаграк укучылар булган. Уку елы, кагыйдә буларак, көзге урып-җыюлардан соң башланып, язгы кыр эшләре алдыннан төгәлләнгән.

Мәктәп-мәдрәсәләр өчен махсус биналар бик сирәк бирелгән, уку, нигездә, шәкертләргә бернинди дә санитария-гигиена шартлары тудырылмаган руханилар йортында барган. Кысан, бөркү бүлмәдә утырганлыктан, шәкертләр йогышлы авырулар белән дә, салкын тиеп тә еш авырганнар. Тән җәзасы бирү гадәти хәл саналган. «Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене «гыйлем» итә торган кеше булган булырга кирәк ки, шул аз мөддәт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп, калтырап торганым бар», – ди Г. Тукай, Кушлавыч авылы мәдрәсәсендә укыган аен искә төшереп[11]. З. Һадиның да шәкертләрнең авыр тормыш шартлары турында язган «Мәгъсүмнең ысулы кадим мәдрәсәсенә укырга баруы» хикәясе бар. Әлеге хикәя Г. Тукай игътибарын җәлеп

тей в национальных и мусульманских традициях. Российское государство не выделяло средств на содержание мусульманских школ, поэтому абыстаи и муллы получали за обучение детей лишь вознаграждение от родителей в виде подарков или подношений (садака). Это могли быть деньги, товары, продукты – в зависимости от имевшихся возможностей, что, кстати, позволяло существовать мектебам и медресе даже «в самых беднейших селениях обширной России»[9]. Вспоминая детство, Г. Тукай писал, что в Кырлае приёмная мать оплатила его учёбу двумя караваями хлеба и деньгами – всего одной или двумя копейками. Самое удивительное то, что маленький Габдулла учился вместе с девочками, хотя, как известно, совместное обучение тогда, казалось бы, не практиковалось. Г. Тукай пишет: «Будущая моя наставница – абыстай – сидела, держа в руке ивовый прут, а возле неё – несколько девочек моего возраста и постарше. Среди них, словно редкие стебельки гороха в пшенице, несколько мальчиков, моих сверстников». Сначала дети заучивали арабский алфавит, затем переходили к чтению «Иман шарты». «Мне хватило её на всю зиму», – вспоминал Г. Тукай. Через год Габдуллу перевели в медресе. Мальчик учился хорошо, «справлялся с заданиями быстро, а потому сидел на занятиях и ничего не делал», поэтому ему стали поручать заниматься с отстающими[10].

Продолжительность курса обучения в медресе зависела от успехов и возможностей каждого ученика и могла длиться десять и более лет. Учебный год, как правило, начинался после осенних и заканчивался перед весенними полевыми работами.

Очень редко под мектебы и медресе использовались специальные общественные здания: как правило, они размещались в домах духовенства, что, естественно, не всегда могло обеспечить необходимые санитарно-гигиенические условия для пребывания здесь учащихся. Теснота, скученность, простудные и инфекционные заболевания сопровождали их во все годы обучения. Обычным делом были телесные наказания. «Я сразу понял, что у хазрата свой способ обучения – это ежедневная порка шакирдов. Без этого, по его мнению, учение в ум не пойдёт. Вид жёсткого истязания мальчиков вызывал у меня дрожь. Мне казалось, что его ивовый прут коснётся и моего тела», – так вспоминал Г. Тукай медресе своей родной деревни Кушлавыч, где он проучился всего один месяц[11]. З. Хади в рассказе «Учёба Максума в кадимистском медресе» детально описал тяжёлые условия жизни шакирдов. Этот рассказ привлёк внимание Г. Тукая, который включил его в свой сборник «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» («Уроки на-

иткән, ул аны үзенең «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгына (1911) да керткән[12].

Кадими мәктәп-мәдрәсәләрне башкача искә алучы шәкертләр дә бар. Мәсәлән, күренекле татар тарихчысы Г. Гобәйдуллин Казанның «Халидия» мәдрәсәсе (ул анда 1890–1900 елларда укыган) турында болай ди: «7 яшьтән мине Казандагы дини мәктәпләрнең берсенә бирделәр, мин анда сигез ел укыдым. Миңа, татар грамотасын укырга кергәнче үк белгәнгә күрә, беренче елны үк Коръән тексты буенча гарәп телен өйрәтә башладылар.

Әйтергә кирәк, ул чордагы инде бераз үзгәргән татар мәктәпләрендә предметларны схоластик мәктәпләрнекенә охшаш программаларга нигезләнеп укытканнар. Гарәпчә укырга һәм язарга өйрәнгәннән соң, миңа аның грамматикасын, синтаксисын укыта башладылар. Аннары мантыйк нигезләрен өйрәнергә керештем. Без аны төрле гарәпчә китаплар буенча укыдык, алар арасында грек философларының тәрҗемәләре дә бар иде. Платон белән Аристотельгә аеруча зур игътибар бирелде. Мантыйк белән бергә диалектиканы, гарәп дин тәгълиматын һәм гарәп хокукын өйрәнә идек.

Ул чорларда мәктәпләрдә формалары һәм темалары буенча Урта гасырлар мәктәпләрен хәтерләтүче диспутлар үткәрелә иде. Алланың барлыгы, фәрештәләр, шайтаннар турында еш бәхәсләшә идек. Диспутка башка мәктәпләрдән дә килүчеләр була. Андый диспутларга яшьтән үк әзерләнү кирәк. Мәсәлән, этимология һәм синтаксисны өйрәнгәндә, башлангыч сыйныфлар дәресләрендә еш утырган укытучылар һәм югары сыйныф укучылары үзләре дә төрле сораулар биреп, грамматик һәм синтаксик анализ өчен буталчык гарәп гыйбарәләрен тәкъдим итәләр иде…

Сигез ел дәвамында мин күп вакытымны мәктәптә үткәрдем. Кояш чыкканчы, иртәнге намаз вакытында китәм дә, төштән соң 2 ләрдә кайтам. 4 тә яңадан китеп, көннең калган өлешен – сәгать 9 га кадәр мәктәптә үткәрәм»[13].

Г. Гобәйдуллинның энесе Кадыйр (1888 елгы) башта мәдрәсәгә абыйсының ничек укыганын карарга гына бара торган була, сәламәтлеге начар булганга, үзе укый алмый. Бу үзенә күрә тормышка психологик әзерлек булган. Мәктәп еллары турында сөйләгәндә, ул, тән җәзасын искә төшереп, болай ди: «Безнең мәдрәсә тормышы беркадәр Киев бурсаклары тормышын хәтерләтә, миңа берничә мәртәбә казыйның үзен тыңламаучыларны

циональной литературы в школе»), опубликованный в 1911 г.[12]

Однако не у всех шакирдов сохранились столь мрачные воспоминания о кадимистских учебных заведениях. Вот как описывал свои школьные годы известный татарский историк Г. Губайдуллин, который в середине 1890-х – начале 1900-х гг. обучался в казанском медресе «Халидия»: «С семи лет меня отдали в одну из казанских татарских духовных школ, где я обучался восемь лет. Так как до поступления в школу я знал татарскую грамоту, то с первого же года меня начали учить арабскому языку по тексту Корана.

Нужно отметить, что тогдашние татарские школы, теперь уже несколько изменённые, имели программу преподавания предметов, очень похожую на ту, которая использовалась в схоластических школах. Так, когда я научился читать и писать по-арабски, мне начали преподавать грамматику и синтаксис этого языка. После этого ознакомился с элементарными сведениями из логики, которую мы проходили до конца курса по различным арабским книгам, среди которых были переводы греческих философов. Особое внимание обращали на Платона и Аристотеля. Вместе с логикой мы изучали диалектику, арабское богословие и арабское право.

В те времена в наших школах проходили диспуты, которые по большей части проводились так, как это было в Средние века и по форме, и по темам спора. Часто спорили о существовании бога, ангелов и сатаны. Обычно принять участие в дискуссиях приходили ученики из других школ. К таким диспутам подготовка велась с молодых лет. Например, когда изучались ещё только этимология и синтаксис, то уже учителя сами или старшие ученики, которые часто присутствовали на уроках младших классов, задавали различные вопросы и предлагали запутанные арабские выражения для грамматического и синтаксического разбора…

В течение восьми лет большую часть времени я проводил в школе. До восхода солнца, во время утренней молитвы я отправлялся туда, а возвращался к двум часам на обед. После обеда, с четырёх часов дня, я опять уходил в школу и весь остаток дня, до девяти часов вечера, проводил там»[13].

Младший брат Газиза Кадыр (род. 1888) писал, что вначале он ходил в медресе «только смотреть», как занимался его брат – сам он не мог учиться из-за слабого здоровья. В какой-то степени это была психологическая подготовка к трудной школьной жизни. Рассказывая о своих школьных годах, он упоминает телесные наказания: «Жизнь наша в медресе отчасти напоминала жизнь киевских бурсаков, не раз я бывал свидетелем, как наш консул («кади») бивал толстой плёткой ослушников его приказаний». В то же время Кадыр Губайдуллин

камчы белән суктыруын күрергә туры килде». Шул ук вакытта К. Гобәйдуллин матур язу укытучысын җылы хисләр белән искә ала: «Укытучым Көнчыгыштагыча бик гыйлемле, гарәп телен һәм әдәбиятын яхшы белә иде. Моннан тыш, ул безне гарәп, төрек, фарсы шрифты белән язарга өйрәтте, аеруча фарсыны якын күрә иде ул, үзе әйтүенчә, фарсы шагыйрьләренең меңгә якын шигырен (күбесе Сәгъдинеке) белә иде[14]. Күренекле татар тел белгече һәм педагог Җ. Вәлиди үзенең 1923 елда басылып чыккан «Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.)» хезмәтендә кадими ысуллы мәктәпләрдә укытуның оештырылуын һәм эчтәлеген тискәре бәяли. Монда сыйныфларга бүленеш булмый, балалар барысы бергә укый. Мәктәпкә көн саен килмиләр: «әти-әниләре аларны мәктәпкә тавышларын ишетмәү өчен генә куып җибәргән». Мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә татарча укыргаязарга өйрәтмәгәннәр: «Татар теленә мәдрәсәләрдә укытыла торган тел дип түгел, мужик теле дип кенә караганнар». Укытучы булып бернинди дипломы булмаган «ярым-йорты белемле карт шәкерт торган»[15]. Әлбәттә, бу очеркның Совет властеның беренче елларында – революциягә кадәрге системадан аерылып торучы яңа укыту системасын актив җәелдерү чорында язылуын истә тоту зарур, әмма дә ләкин бу хезмәттә авторның иске ысуллы мәктәпкә тискәре карашы нык сизелә.

Соңрак өйрәнү-тикшеренү әдәбиятында кадими уку йортлары артта калган, шул чорның белем бирү дәрәҗәсенә туры килми дип тәнкыйтьләнә. Чынлыкта исә, кадими система татар милли мәктәпләре һәм педагогик фикер үсешендә котылгысыз һәм законча лыклы этап булган. Аның нигезендә җәдитчелек үсеш ала. Татар әдәбиятын, милли тарихыбызны үстерүгә зур өлеш керткән һәм XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында җәдиди реформалар уздырган татар зыялылары (Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин, Һ. Атласи, Г. Тукай һ. б.) нәкъ менә кадими ысуллы мәктәпләрдә белем алганнар.

Яңа ысуллы (җәдит) мәктәпләрдә укыту башка принциплар нигезендә алып барылган. Мәктәп һәм мәдрәсәләргә бүлү элеккечә сакланган, ләкин мәдрәсәгә бик тикшереп алганнар. 1913 елның 26 июль санында «Вакыт» газетасы Казанда Г. Баруди нигез салган җәдитчә укыта торган иң данлыклы уку йортларының берсе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә кабул итү турында игълан басты-

с теплотой вспоминал своего учителя чистописания: «Учитель чистописания был по-восточному образованный человек, знавший хорошо арабский язык и литературу. Кроме того, он учил писать разными шрифтами: арабским, турецким, персидским, особенно красиво последним, потому что увлекался всем персидским и знал, по его словам, до тысячи стихов из персидских поэтов, больше всего из любимого поэта Саади»[14].

В опубликованном в 1923 г. «Очерке истории образованности и литературы татар (до Октябрьской революции 1917 г.)» известный татарский языковед и педагог Дж. Валиди (1887–1932) оценивал организацию и содержание обучения в кадимистских учебных заведениях весьма скептически. В старометодных образовательных учреждениях отсутствовало деление на классы, все дети занимались вместе, посещали школу нерегулярно: «родители обыкновенно гнали их в школу только для того, чтобы избавиться от их шума и гама». В мектебах и медресе не обучали татарской грамоте: «Татарский же язык в медресе считается предметом, не достойным изучения, его презирали как язык мужиков». Учителем выступал «полуграмотный старый шакирд, не получивший, конечно, никакой педагогической подготовки и не имевший никакого диплома»[15]. Конечно, необходимо учитывать, что этот очерк был написан в первые годы советской власти, когда развернулось активное строительство новой системы школьного образования, в которой прежней дореволюционной, и уж тем более религиозной школе не было места, однако резко негативная оценка преподавания в старометодных школах была здесь налицо.

Позднее в исследовательской литературе кадимистские учебные заведения также часто критиковались как отсталые и не соответствующие уровню образования своего времени. На самом же деле кадимистская система была необходимым и закономерным этапом в развитии татарской национальной школы и педагогической мысли. На основе её и выросло впоследствии джадидское образование. Именно в кадимистских учебных заведениях получила образование будущая татарская интеллигенция (Ш. Марджани, Р. Фахрутдинов, Х. Атласи, Г. Тукай и др.), которая сыграла значимую роль в развитии татарской литературы, национальной истории и проводила джадидские реформы в конце XIX – начале XX в.

В новометодных (джадидских) школах обучение осуществлялось по совершенно иным принципам. Деление на мектебы и медресе по-прежнему сохранялось, но при поступлении в медресе осуществлялся довольно жёсткий отбор. 26 июля 1913 г. газета «Вакыт» («Время») опубликовала объявление о приёме в начальные («ибтидаия») и средние

ра. Анда сүз башлангыч («ибтидаи») һәм урта сыйныфларга («рөшди») кабул итү турында бара. Рөшди сыйныфларга дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлаган 12 яшьлек балалар кабул ителгән. Алар Коръәнне дөрес уку, төрки китапларны уку һәм аңлау, дөрес язу, арифметиканың дүрт гамәле, географиянең башлангыч курсы, ислам тарихы һәм русча укый белү буенча имтиханнар бирергә тиеш булганнар. Димәк, бала әлеге белем һәм күнекмәләрне башлангыч мәктәптә үк үзләштерергә тиеш дип саналган. Моннан тыш, мәдрәсәгә укырга керүче баладан сәламәтлеге турында белешмә, паспорт, ата-анасы яисә тәрбиячеләреннән рөхсәт язуы һәм Казанда яшәве турында раслау кәгазе сораган[16].

Яңа ысул белән укыту дөньяви предметлар һәм рус телен укыту белән чикләнми, сыйныфлап дәрес бирүне дә, махсус җиһазландыруны (парталар, сыйныф тактасы һ.б.) да күздә тоткан. Мәдрәсәдә хәзер мулла түгел, ә укытучы укыткан. Г. Тукайның «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару» хикәясе герое Ибраһимны «көләч йөзле, мөлаем» укытучы «шәфкатьле һәм җылы сүзләр белән» үз янына чакыра. Ул Ибраһимның исемен дәфтәргә язып куя, «кулыннан тотып, сыйныфка алып чыгып», партага утырта, «ушбу көннән башлап Ибраһим «урам баласы»лыктан чыгып, мәктәп шәкерте булып китте»[17].

классы («рушдие») одного из самых популярных джадидских учебных заведений Казани – медресе «Мухаммадия», основанной Г. Баруди. В рушдие принимались дети, закончившие четырёхлетнюю начальную школу в возрасте 12 лет. Они должны были сдать экзамены по правильному чтению Корана, чтению и пониманию тюркских книг, правильному письму, четырём действиям арифметики, начальному курсу географии, истории ислама и продемонстрировать «умение читать по-русски». Таким образом, подразумевалось, что все эти знания и умения дети получили уже в начальной школе. Кроме того, поступающим следовало представить медицинское свидетельство о состоянии здоровья, паспорт, разрешение от родителей или воспитателей и подтверждение о проживании в Казани (в том году иногородние в это медресе не принимались)[16].

Новый метод предполагал не только изучение светских предметов и русского языка, но и введение классно-урочной системы и использование специального классного оборудования (парты, классная доска и др.). Обучением занимался отныне не мулла, а учитель. Героя рассказа Г. Тукая «Первый раз в школу» – мальчика Ибрагима, «тёплыми, ласковыми словами» встретил в школе «симпатичный улыбчивый человек». Он записал Ибрагима в тетрадь, «ввёл в класс и посадил за парту… С этого дня Ибрагим перестал быть уличным мальчишкой и превратился в шакирда»[17].



• Казан губернасы Тәтеш шәһәрендә рус-татар мәктәбендә дәрес вакыты. XX гасыр башы (П. А. Чекмарёвның «Есть на Волге городок. Из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана» китабыннан. Казан, 2004)

• Занятия в русско-татарской школе г. Тетюши Казанской губернии. Начало XX в. (из книги П. А. Чекмарёва «Есть на Волге городок. Из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана». Казань, 2004)

ЭЧТӘЛЕК

Фәнни мөхәррирдән 4
Авторлардан 5

I бүлек

«Иман шарты»ннан яңа төр әлифбага: XIX гасыр ахыры — XX гасыр башы татар «Әлифба»сы 7

1. «Яңа» татар әлифбасы һәм аның үзенчәлекләре 9
2. «Харитон бабай әлифбасы» һәм рәсемле башка татар әлифбалары 43

II бүлек

«Әлифба» революциясе һәм әлифбадагы революция: совет мәктәбендәге «Әлифба» 63

1. Түбәтәйле яланаяк пионерлар: балалар өчен беренче татар совет әлифбалары ... 65
2. «Бетсен наданлык!» Зурлар өчен беренче татар совет әлифбалары 78
3. «Мәсьәлә хәл ителгән...»: төрки әлифбаларны латинлаштыру һәм 1920—1930 еллар ахыры татар әлифбасы 90
4. Тотрыклы дәреслеккә таба: 1930 еллар башында мәгариф реформалары һәм татар әлифбасын бердәйләштерү 112
5. «Минем әти — герой-командир»: 1930 еллар ахыры — 1950 еллар татар әлифбасы ... 132
6. Р. Г. Вәлитова һәм С. Г. Вагыйзов «Әлифба»сы «идеаль» татар совет әлифбасымы? 153

III бүлек

«Яңа чынбарлык» чагылышы буларак советлардан соңгы чор «Әлифба»сы 165

ОГЛАВЛЕНИЕ

От научного редактора 4
От авторов 5

Глава I

От «азбуки с молитвами» к букварю нового типа: татарская «Алифба» конца XIX — начала XX в. 7

1. «Новый» татарский букварь и его особенности 9
2. «Букварь дедушки Харитона» и другие иллюстрированные татарские буквари 43

Глава II

«Букварная» революция и революция в букваре: «Алифба» в советской школе 63

1. Босоногие пионеры в тюбетейках: первые советские татарские буквари для детей 65
2. «Долой неграмотность!» Первые советские татарские буквари для взрослых 79
3. «Считая вопрос разрешённым»: латинизация тюркских алфавитов и татарский букварь конца 1920-х — 1930-х гг. 91
4. К стабильному учебнику: образовательные реформы начала 1930-х гг. и унификация татарского букваря 111
5. «Мой папа — герой-командир»: татарский букварь конца 1930-х — 1950-х гг. 132
6. «Алифба» Р. Г. Валитовой и С. Г. Вагизова: «идеальный» татарский советский букварь? ... 153

Глава III

Постсоветская «Алифба» как отражение «новой реальности» 165

УДК 373.3.16
ББК 74.23(2)4; 74.268.1
С16

Рус телендәге басманың фәнни мөхәррире
педагогика фәннәре докторы, РМАның Мәгариф үсеше стратегиясе институты баш фәнни хезмәткәре, РМА әгъза-корреспонденты ***В. Г. Безрогов***

Татар телендәге басманың фәнни мөхәррире
тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФАның Татар энциклопедиясе һәм регионнарны өйрәнү институты каршындагы Энциклопедистика үзәге җитәкчесе ***Р. В. Шәйдуллин***

Научный редактор (на русском языке)
доктор педагогических наук, главный научный сотрудник Института стратегии развития образования РАО, член-корреспондент РАО ***В. Г. Безрогов***

Научный редактор (на татарском языке)
доктор исторических наук, профессор, руководитель Центра энциклопедистики Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ ***Р. В. Шайдуллин***

Сальникова, А. А.

С16 Татар «Әлифба»сы : үткәне һәм бүгенгесе / А. А. Сальникова, Д. М. Галиуллина ; [русчадан Х. Г. Фәйзрахманова тәрҗ.] : монография. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. — 196 б.

ISBN 978-5-298-03277-3

Хезмәт татар халкының тарихи һәм мәдәни ядкяре «Әлифба» китабына багышлана. Төп игътибар XIX гасыр азагы — XXI гасыр башында Казан губернасы, совет чоры, советлардан соңгы чор Татарстанында гамәлдә булган басмаларга юнәлтелә. Алар — татар халкының үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыручы уникаль чыганаклар. Монографиядә империячел, совет һәм советлардан соңгы чорларда Россия һәм Татарстандагы сәяси һәм иҗтимагый-мәдәни үзгәрешләрнең әлифба тексты һәм иллюстрацияләрендә ни дәрәҗәдә чагылуы һәм шуның нәтиҗәләре өйрәнелә, балачак һәм балалар, аларның олылар дөньясындагы роле күзәтелә. Өйрәнү-тикшеренү нәтиҗәләре фәнни яктан да, башлангыч мәктәп өчен яңа төр дәреслекләр әзерләүдә дә зур гамәли әһәмияткә ия.

Сальникова, А. А.

С16 Татарская «Алифба»: история и современность / А. А. Сальникова, Д. М. Галиуллина ; [пер. на татар. яз. Х. Г. Файзрахмановой] : монография. — Казань : Татар. кн. изд-во, 2016. — 196 с.

ISBN 978-5-298-03277-3

Книга посвящена татарскому букварю «Алифба» как уникальному памятнику истории и культуры. Основное внимание уделено изданиям конца XIX — начала XXI в., функционировавшим в культурном пространстве Казанской губернии, советской Татарии, постсоветского Татарстана. Они являются выразителями духа своего времени, носителями ценнейшей информации о прошлом и настоящем татарского народа. В монографии рассматриваются результаты и способы отражения в текстах и иллюстрациях букварей тех общественно-политических и социокультурных трансформаций, которые происходили в имперской, советской и постсоветской России и в Татарстане в рассматриваемый период, прослеживаются изменения представлений о детстве и детях и их роли и месте в большом, «взрослом» мире. Результаты исследования, помимо научно-познавательного, имеют и прикладное значение в практике подготовки нового поколения учебников для начальной школы.

Фәнни-популяр басма

Сальникова Алла Аркадьевна
Галиуллина Диләрә Мәгъзум кызы

ТАТАР «ӘЛИФБА»СЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2016
Татар һәм рус телләрендә

Мөхәррирләре *И. И. Кадыйрова, И. Ф. Сафин*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Р. Н. Нуриева, А. Р. Миңнуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 07.12.2016.
Форматы 60×90 1/8. Басма табагы 24,5.
Тиражы 2200 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ ФИРМА КИБЕТЛӘРЕ:

Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет:
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

ISBN 978-5-298-03277-3

© Сальникова А. А., Галиуллина Д. М., 2016
© Татарстан китап нәшрияты, 2016

Научно-популярное издание

Сальникова Алла Аркадьевна
Галиуллина Диляра Магзумовна

ТАТАРСКАЯ «АЛИФБА»: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОСТЬ

Казань. Татарское книжное издательство. 2016
На татарском и русском языках

Редакторы *И. И. Кадырова, И. Ф. Сафин*
Художественный редактор *Р. Х. Хасаншин*
Технический редактор и компьютерная верстка *М. И. Данилевской*
Корректоры *Р. А. Файзуллина, Р. Н. Нуриева, А. Р. Миннуллина*

Оригинал-макет подписан в печать 07.12.2016. Формат 60×90 1/8.
Печ. л. 24,5. Тираж 2200 экз. Заказ

ГУП РТ «Татарское книжное издательство».
420066. Казань, ул. Декабристов, 2. Тел./факс: (843) 519-45-22.

ФИРМЕННЫЕ МАГАЗИНЫ ТАТАРСКОГО КНИЖНОГО ИЗДАТЕЛЬСТВА:

Казань, ул. Баумана, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казань, ул. Баумана, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казань, ул. Декабристов, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Отдел маркетинга:
Казань, ул. Декабристов, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-магазин:
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

УДК 373.3.16
ББК 74.23(2)4; 74.268.1

© Сальникова А. А., Галиуллина Д. М., 2016
© Татарское книжное издательство, 2016